| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 нче июль Мөрәле авылы № 35

Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 октябрендәге 30 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә 7 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, ул килешүгә кул куелганчы, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр.».

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2014 елның 14 октябрендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә, 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«в) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, һәм алар хисабына алыш-биреш ясалган керем алу чыгынаклары турында килешү төзелгән хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), белешмәләр.»;

3. Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 7 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен мәгълүмат бирү тәртибенең 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, һәм алар хисабына алыш-биреш ясалган керем алу чыгынаклары турында килешү төзелгән хисап чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), белешмәләр.».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru, авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннәтуллин